ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.06.2022 г.Мензелинск № 217

Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләүгә ата-ана түләве буенча ташламалар бирү турында

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 29.12.2012 N 273-ФЗ Федераль закон, 29.12.2012 N 273-ФЗ Федераль законның 20 ст.5 мад., Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Уставы, РФ Эчке эшләр министрлыгының Минзәлә районы буенча бүлегенең үтенечнамәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве буенча 01.07.2002 елдан 50% ка түбәндәге категория хезмәткәрләргә ташламалар бирергә :

1.1. Минзәлә районы буенча РФ Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре (федераль дәүләт гражданлык хезмәткәрләреннән һәм ирекле ялчылардан тыш)

1.2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләре:

- Тәрбияче ярдәмчесе
-Кер юучы
-Ишегалды жыештыручы
-Эш җитештерүче
- Хуҗалык мөдире
-Кастелянша
-Кухня хезмәткәре
-Пешекче.
-Ярдәмче эшче

- Комплекслы хезмәт күрсәтү һәм биналарны төзәтү буенча эшче
- Слесарь - электрик
- Каравылчы
- Җитештерү һәм хезмәт бүлмәләрен җыючы

2. Түләнүче суммалар буенча чыгымнарны белем бирү оешмасының агымдагы сметасы исәбеннән кире кайтарырга.

3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләүгә ата-аналар түләве буенча ташламалар бирү турында» 29.12.2014 № 1317карары үз көчен югалткан дип таныргa

4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Мәгариф бүлеге» МКУ җитәкчесе Л.В.Петраевка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Кәримов